МИНИСТЕРСТВО
ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Государственное автономное
образовательное учреждение
дополнительного профессионального
образования
«ИНСТИТУТ РАЗВИТИЯ
ОБРАЗОВАНИЯ РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН»
ул. Б.Красная, д.68, г. Казань, 420015

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН
МИНИСТРЛЫГЫ

Өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт
автоном мәгариф учреждениесе

«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ
ИНСТИТУТЫ»
Зур Кызыл ур., 68 нче йорт, Казан ш., 420015

Тел.: (843) 236-62-42, факс: 236-62-42, e-mail: irort2011@gmail.com, сайт: http://irort.ru

26.10.2022 № 567/22

На № ________________ от ______________

Белем бирү оешмалары
житәкчеләренә

Фәнни-гамәли конференция үткәрү турында

«Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениесе, "Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының мәгариф идарәсе" муниципаль казна учреждениесе, Казан шәһәренең Ш.Мәржани исемендәге 2нче татар гимназиясе белән берлектә, 2022нче елның 2нче декабрендә фәннәрне татар телендә укытуның үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге турында сөйләшү, фикер алышу максатыннан "Предметларны татар телендә укыту: традицияләр һәм яңалыклар" дип исемләнгән фәнни-гамәли конференция үткәрә.

Гаризаларны һәм эшләрне кабул итү – shgul-79@mail.ru адресына 2022нче елның 21нче ноябренә кадәр дәвам итә.

Белешмәләр өчен телефоннар: 8(843)236-68-11, 89872190025, Татарстан Республикасы Казан шәһәре Мәгарифне үстерү институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы доценты, филология фәннәре кандидаты Шакирова Гөлназ Марс кызы.

Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү
институтының беренче проректоры Р.Г. Хәмитов

Кушымта

**“Предметларны татар телендә укыту: традицияләр һәм яңалыклар” фәнни-гамәли конференциясе нигезләмәсе**

## I. Гомуми мәгълүмат

“Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты” өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениесе, “Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының мәгариф идарәсе” муниципаль казна учреждениесе, Казан шәһәренең Ш.Мәрҗани исемендәге 2нче татар гимназиясе белән берлектә, фәннәрне татар телендә укытуның үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге турында сөйләшү, фикер алышу максатыннан “Предметларны татар телендә укыту: традицияләр һәм яңалыклар” фәнни-гамәли конференция (түгәрәк өстәл форматында) үткәрә.

## Максат һәм бурычлар

- Педагогик җәмәгатьчелекнең игътибарын татар теленең функциональ мөмкинлекләренә, төрле фәннәрне татар телендә укыту тарихына, традицияләренә юнәлтү, бүгенгесенә күзәтү ясау, киләчәк үсешен билгеләүгә тарту;

- милли мәгарифтәге актуаль мәсьәләләрне күтәрү;

- иҗади һәм инновацион укыту алымнарын кулланучы мәгариф хезмәткәрләрен таныту, аларның эшләрен җәмәгатьчелек тарафыннан хуплау;

- конференциядә катнашучыларда халкың, туган телең, аның тарихы, шәхесләре белән горурлану хисләре тәрбияләү.

## Конференциядә катнашучылар:

- Гомуми белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләре катнаша ала.

- Конференциядә катнашу ирекле. Катнашучы үз-үзен тәкъдим итәргә хокуклы.

- Мәктәпләрдән конференциядә катнашучылар саны чикләнми.

- Катнашучының яше, квалификация категориясе буенча чикләүләр юк.

## Юнәлешләр:

- Татар халкының милли мәгариф тарихы.

- Фәннәрне татар телендә укытуда традицияләр һәм яңалыклар.

Гаризалар һәм түгәрәк өстәлдә ясалачак чыгышларның темалары 2022нче елның 21нче ноябренә кадәр кабул ителә.

**Конференциядә катнашу турында Сертификат алу тәртибе:**

**Конференциядә** катнашу турында сертификат, катнашучының теләгенә карап, басма яки электрон форматта эшләнә.

**Белешмәләр өчен электрон адрес һәм телефоннар:** shgul-79@mail.ru, 8(843)236-68-11, 89872190025 (Шакирова Гөлназ Марс кызы).

**"Предметларны татар телендә укыту: традицияләр һәм яңалыклар" республика фәнни-гамәли конференциясендә катнашу өчен гариза**

| Эшнең темасы | Авторның фамилиясе, исеме, атасының исеме (тулы килеш татар телендә) | Оешманың тулы исеме (устав буенча татар телендә) | Элемтә өчен телефон | Электрон почта |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |